Татарстан Реcпубликасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге Советының уникенче утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

14 декабрь, 2021 ел № 36

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Белкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 11 гыйнварындагы 72 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Белкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 11 гыйнварындагы 72 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге Советы карары (2018 елның 14 декабрендәге 103 номерлы карары, 2020 елның 1 сентябрендәге декабрендәге 142 номерлы карары белән кертелгән үзгәреш белән) үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге башлыгы А.Н. Меньшов